Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлеге Советы

Шәле авыл җирлеге башлыгы
# КАРАРЫ

1 октябрь, 2024 ел № 5

Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлеге уставының 23 статьясы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда (торак пункт территориясе өлешендә) гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы 2019 елның 08 ноябрендәге 59 номерлы (2021 елның 14 декабрендәге 33 номерлы карар белән расланган үзгәрешләр белән), имзалар кәгазьләре нигезендә Шәле авыл җирлеге Советы карары нигезендә **карар кабул итте:**

1. Шәле авыл җирлегендә түбәндәге торак пунктларда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләргә:

1.1.Шәле авылында. Унбиш этапта гражданнар җыенын уздырырга:

- гражданнар җыенының беренче этабы 2024 елның 14 октябрендә 9 сәгать 00 минутта Яшьләр урамы, 1 йорт янында. Җыенда катнашучылар исемлегенә Урман, Яшьләр, Тау, Подгорная урамнарында теркәлгән халыкны кертергә;
- гражданнар җыенының икенче этабы 2024 елның 14 октябрендә 11 сәгать 00 минутта Тукай урамы, 25 йорт янында. Җыенда катнашучылар исемлегенә Тукай урамының 1 дән 61 кадәр йортларда теркәлгән халыкны кертергә;
- гражданнар җыенының өченче этабы 2024 елның 14 октябрендә 14 сәгать 00 минутта КамАЗ урамы, 22 йорт янында. Җыенда катнашучылар исемлегенә КамАЗ, Яңа урамнарында теркәлгән халыкны кертергә;
- гражданнар җыенының дүртенче этабы 2024 елның 14 октябрендә 16 сәгать 00 минутта Таҗиев урамы, 21 йорт янында. Җыенда катнашучылар исемлегенә Таҗиев, Тукай урамының 61а дан 99 кадәр йортларда теркәлгән халыкны кертергә;
- гражданнар җыенының бишенче этабы 2024 елның 15 октябрендә 10 сәгать 00 минутта Тукай урамы, 131 йорт янында. Җыенда катнашучылар исемлегенә Тукай урамының 100 дән 161 кадәр йортларда теркәлгән халыкны кертергә;

- гражданнар җыенының алтынчы этабы 2024 елның 15 октябрендә 13 сәгать 00 минутта Почта урамы, 28 йорт янында. Җыенда катнашучылар исемлегенә Почта, Шәле тыкрыгы урамнарында теркәлгән халыкны кертергә;

- гражданнар җыенының җиденче этабы 2024 елның 15 октябрендә 16 сәгать 00 минутта Ленин урамы, 31 йорт янында. Җыенда катнашучылар исемлегенә Совет, Ленин урамнарында теркәлгән халыкны кертергә;

- гражданнар җыенының сигезенче этабы 2024 елның 16 октябрендә 10 сәгать 00 минутта Вәхит урамы, 33 йорт янында. Җыенда катнашучылар исемлегенә Вәхит урамында теркәлгән халыкны кертергә;

- гражданнар җыенының тугызынчы этабы 2024 елның 16 октябрендә 13 сәгать 00 минутта Казан урамы, 19 йорт янында. Җыенда катнашучылар исемлегенә Казан, М.Шәйхиева, Г.Сафиуллин, Ф. Сафин, М. Мөхәмәтҗанова, Җиңү, Отрадная, Кыр урамнарында теркәлгән халыкны кертергә;

- гражданнар җыенының унынчы этабы 2024 елның 16 октябрендә 16 сәгать 00 минутта Кәвәл урамы, 8 йорт янында. Җыенда катнашучылар исемлегенә Хәйруллин, Кәвәл, Кооператив урамнарында теркәлгән халыкны кертергә;

- гражданнар җыенының унберенче этабы 2024 елның 17 октябрендә 10 сәгать 00 минутта Кызыл Йолдыз урамы, 37 йорт янында. Җыенда катнашучылар исемлегенә Кызыл Йолдыз урамында теркәлгән халыкны кертергә;

- гражданнар җыенының уникенче этабы 2024 елның 17 октябрендә 13 сәгать 00 минутта Һади Такташ урамы, 47 йорт янында. Җыенда катнашучылар исемлегенә Һади Такташ урамында теркәлгән халыкны кертергә;

- гражданнар җыенының унөченче этабы 2024 елның 17 октябрендә 16 сәгать 00 минутта Муса Җәлил урамы, 22 йорт янында. Җыенда катнашучылар исемлегенә Муса Җәлил урамында теркәлгән халыкны кертергә;

- гражданнар җыенының ундүртенче этабы 2024 елның 18 октябрендә 10 сәгать 00 минутта Дуслык урамы, 36 йорт янында. Җыенда катнашучылар исемлегенә Дуслык урамында теркәлгән халыкны кертергә;

- гражданнар җыенының унбишенче этабы 2024 елның 18 октябрендә 13 сәгать 00 минутта Чокыр урамы, 12 йорт янында. Җыенда катнашучылар исемлегенә Чокыр урамында теркәлгән халыкны кертергә;

«Сез, 2025 елда Шәле торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 группа инвалидларны, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылар, Бөек Ватан сугышында һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарын, сугыш һәм хәрби хәрәкәтләрендә катнашучыларны, 80 яшькә җиткән гражданнарны, махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүп-чарларны бетерү

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.2. Шәле авыл җирлеге ТатЦИК исемендәге авылда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2024 елның 18 октябрендә 16.00 сәгатьтә Совет урамы, 12а йорт адресы буенча урнашкан кибет бинасы янында уздырырга.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез, 2025 елда ТатЦИК исемендәге торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 группа инвалидларны, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылар, Бөек Ватан сугышында һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарын, 80 яшькә җиткән гражданнарны, махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- торак пункт территориясен төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Шәле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

Питрәч муниципаль районы
Шәле авыл җирлеге башлыгы И.Р. Әхмәтҗанов

СОВЕТ ШАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ